**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2023 елның «19» гыйнвары

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелде, 2022 елның 5декабрендәге 85-РС номерлы карары белән билгеләнде.

Пәрәү авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2022 елның 5декабрендәге 85-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде:

1. 2022 елның 8 декабрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2022 елның 8 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;
3. 2022 елның 7 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 19 декабрендәге 8481/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр 2022 елның 19 декабрендәге 8481/исх номерлы белдерүе басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2022 елның 21 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлегенең рәсми сайтында;
2. 2022 елның 21 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);
3. 2022 елның 21 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Тимергалиев Фаниль Фаритофич - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге башлыгы:.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2023 елның«19»гыйнварындагы Пәрәү авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 6 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:

1. Халык тыңлауларын үткән дип таныга;
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын, 2023 елның«19»гыйнварындагы ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә;
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнар нигезендә әлеге бәяләмәдән өземтә бирүне гамәлгә ашырырга.

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре ________________________ Тимергалиев Ф.Ф.